

Коз коне бакчада эш аз тvгел. Агач-куакларнын картайган ботакларын кисеп алырга. Кискән урыннарын бакчада кулланыла торган кайнатылган сумала яки майлы буяу белән буяп куярга. Кояшлы кондә жимеш агачлары кәvсәләрен агартып чыгабыз. Анын очен шулай ук махсус эшләнгән акрил буяу кулланырга була. Бу буяу очен янгырлар куркыныч тvгел.      Быел коз бик коры килде, шунын очен жимеш агачлары белән куакларга яхшылап су сибәбез. Кvпьеллык чәчәкләрне дә суга туендырып калу зарур. Коздән суган белән сарымсак утыртып калдырабыз. Сарымсакны утыртмаган булсагыз, ашыгыгыз. Козге суганны жир тунарга атна-ун кон кала утыртасы була.
Жимеш агачларын козен сентябрь азагыннан октябрь уртасына кадәр, жылы һава торышы булганда утырталар. Ин яхшысы – яфраклар коелып беткәч. Шулай ук жир суынып бетмәсен, агач тамырлары 4 градуска кадәр жылы булганда vсә. Шуны истә тотыгыз – ботен жимеш агачларын да козен утырт-мыйлар. Кышны груша, алмагач, чия, алыча, миләш, себер сливасы яхшы кышлый. Ә менә абрикос, персик, точе чия (черешня) агачларын язын утырту хәерле, ди тәжрибәле бакчачылар. Яшь vсенте янына таяк утыртып, бәйләп кую хәерле. Аннары 3 литр жылы су сибегез. Дым кибvне акрынайту очен, агач тобенә мульча салыгыз, чонки агачны салкыннардан саклый. Барлык агачларны коз коне акка буяп калдырсагыз яхшы булыр, дигән кинәштә Мордовия бакчачылары.
Менә эшләрнен берничәсе генә. Тагы чvп vләннәрдән арыну да бик тә кирәкле эшләрнен берсе. Жирне сукалап калдырсан, киләсе елда берничә проблемадан арынасын дигән сvз: жир йомшара, чvп vлән тамырлары vлә, божәкләр кими...
Коз быел жылысы белән кvнелгә хуш килде. Бакчаларда планлаштырган эшләрне башкарып чыгарга да унай.

**Наилә НАСЫРОВА**